КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 декабрь г.Казань № 1100

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «196», «879,207», «52», «276,071», «144» һәм «603,136» саннарын тиешенчә «199», «3629,474», «56», «1173,763», «143» һәм «2455,711» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

3.3 пунктның унсигезенче абзацында «гамәлгә ашыра» сүзләре алдыннан «төбәк» сүзен өстәргә;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инспекция башлыгын вазыйфага билгеләүне һәм вазыйфадан азат итүне килештеү «Күпфатрлы йортларны һәм күчесез милекнең бүтән объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 2.2 өлеш нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе структурасы

